РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1088 26 октябрь 2015 ел.

Түбән Кама муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган һәм башкарыла торган хезмәтләрнең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләрен формалаштыру һәм алып бару, федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган һәм башкарыла торган дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау турында, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә торган һәм башкарыла торган хезмәтләрнең һәм дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең ведомство исемлеген формалаштыруга, алып баруга һәм раслауга гомуми таләпләр турында» 2014 елның 26 февралендәге 151 номерлы карарын (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 151 номерлы карары) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 518 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, карар бирәм

1. Түбән Кама муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган һәм башкарыла торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибен (алга таба - Тәртип) (кушымта) расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге структур бүлекчәләренә Түбән Кама муниципаль районы ведомство карамагындагы муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган муниципаль хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм актуаль хәлдә тоту вәкаләтләрен бирергә:

-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе;

-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;

- Түбән Кама Башкарма комитетының мәгариф идарәсе

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсе.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләренә 2015 елның 30 октябренә кадәр әлеге карарның 1 пункты белән расланган Тәртип нигезендә Түбән Кама муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыруны тәэмин итәргә.

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлегенә 2015 елның 30 ноябренә кадәр әлеге карарның 1 пункты белән расланган Тәртип нигезендә Түбән Кама муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлеген раслауны тәэмин итәргә.

5. 2016 елга (2016 елга һәм 2017, 2018 еллар план чорына) муниципаль йөкләмәләрдән башлап, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга муниципаль йөкләмәләрне формалаштыру әлеге карар белән расланган Тәртип нигезендә формалаштырылган муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен кулланып гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Хөсәеновка йөкләргә.

В.В.Федотов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесене
2015 елның 26 октябрендәге
1088 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру алып бару һәм раслау тәртибе

1. Әлеге документ Түбән Кама муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру алып бару һәм раслау тәртибен билгели.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлекләре әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан формалаштырыла, алып барыла һәм актуаль хәлдә тотыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәи эшләрнең ведомство исемлекләре Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

3. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 статьясындагы 3.1 пункты нигезендә формалаша һәм алып барыла.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлекләренә һәр муниципаль хезмәт күрсәтү һәм эшләргә карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 февралендәге 151 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренең һәм эшләренең ведомство исемлеген формалаштыруга, алып баруга һәм раслауга гомуми таләпләрнең 3 пунктында китерелгән мәгълүмат кертелә.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә һәр муниципаль хезмәт күрсәтү һәм эш буенча формалаштырылган мәгълүмат муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлегенең реестр язмасын (алга таба – реестр язмалары) төзи.

6. Реестр язмаларын формалаштыру өчен башлангыч мәгълүмат:

- Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр төзегәндә исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләрнең (эшләрнең) якынча исемлеге (алга таба-муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең якынча исемлеге)

- гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органга караган муниципаль учреждениеләр исемлеге;

- муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең эчтәлеге һәм шартлары (формалары), муниципаль учреждениеләр уставларында каралган ведомство карамагындагы һәр учреждение буенча эшләр башкару һәм асылда гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләр турында мәгълүмат;

- Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләр сыйфатын бәяләү күрсәткечләренең якынча исемлеге (2016 елның 1 июленә кадәр).

7. Реестр язмалары әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт (муниципаль) хезмәтләренең һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен формалаштырганда, алып барганда һәм раслаганда, реестр язмасына һәм реестр язмасының уникаль номерының структурасына кертү өчен мәгълүматны һәм документларны формалаштыру тәртибен кертеп, реестр язмаларын формалаштыру (үзгәртү) тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 174н номерлы боерыгы (алга таба - 174н номерлы боерык) билгеләгән тәртиптә формалаштырыла һәм алып барыла.

8. Реестр язмалары 174н номерлы боерык белән расланган Тәртиптә аңа керү Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталы аша - www.budget.gov.ru (алга таба – Мәгълүмат системасы) башкарыла торган «Электрон бюджет» җәмәгать финанслары белән идарә итүнең интеграцияләнгән дәүләт мәгълүмат системасында электрон формада формалаша. Муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләре шулай ук «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлеген, федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган һәм башкарыла торган дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм эшләрнең ведомство исемлеге, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә торган һәм башкарыла торган хезмәтләрнең һәм дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләрнең ведомство исемлеге дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре турында мәгълүмат урнаштыру буенча «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта (www.bus.gov.ru) урнаштыру Тәртибен раслау турында» 2014 елның 17 декабрендәге 152н номерлы боерыгы белән расланган Тәртиптә урнаштырыла һәм саклана.

9. Реестр язмаларына үзгәрешләр әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан 174н номерлы боерык белән расланган тәртиптә, карар кабул ителгәннән соң ун көн эчендә кертелә:

-муниципаль эшләрне башкаручы, муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль учреждениене төзү, үзгәртеп кору, гамәлдән чыгару турында;

- муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү күрсәткечләрен үзгәртү турында;

- муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлеген үзгәртү турында.

10. Реестр язмасына кертү өчен мәгълүмат һәм документлар, уникаль номер структурасы 174н номерлы боерык белән билгеләнгән кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

11. Реестр язмаларына гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органы исеменнән эш итәргә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салына.

12. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, кирәк булган очракта, база (тармак) хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерлиләр. Хезмәтләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр:

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә рәсмиләштерелә;

- эш тәртибендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелә;

- Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт сәясәтен эшләү һәм билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә норматив хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы тиешле федераль башкарма хакимият органына карап тикшерүгә җибәрелә.